**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

11.12.2017 № 719

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында» 2011 елның 14 апрелендәге 172 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 28 апрелендәге 181 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 24 июлендәге ПУ-617 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 13 сентябрендәге 444 номерлы, 2013 елның 6 ноябрендәге 537 номерлы, 2014 елның 5 августындагы 469 номерлы, 2014 елның 10 декабрендәге 697 номерлы, 2015 елның 15 августындагы 462 номерлы, 2016 елның 16 маендагы 294 номерлы, 2016 елның 22 декабрендәге 743 номерлы, 2017 елның 28 апрелендәге 258 номерлы һәм 2017 елның 7 июлендәге 427 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле $13^6$ пункты өстәргә:

«$13^6$. Әлеге Нигезләмәнең $13^1$, $13^3$ һәм $13^4$ пунктларында күрсәтелгән дәлилле бәяләмәләрдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 12 пункты «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә һәм хәбәрнамәләрдә бирелгән мәгълүмат;

б) соратулар нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 12 пункты «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрнамәләрне алдан карап тикшерү нәтиҗәләре буенча дәлилле бәяләмә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 20, $21^{3}$, $22^{1}$ пунктлары нигезендә карарларның берсен яисә башка карар кабул итү өчен тәкъдимнәр.»;

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия составында Л.Р. Зиннәтуллинаның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: « Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының кадрлар бүлеге мөдире, Комиссия секретаре».

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**